**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423740,село Актаныш, проспект Ленина,дом 58,тел.3-44-40

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 нче йорт, тел.3-44-40

**КАРАР**

№ 34 «30» ноябрь 2020 ел

**Актаныш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм куллану турында**

**«**Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25,1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, халык җыены беркетмәсе нигезендә Актаныш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Актаныш авыл җирлеге территориясендә 2021 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүләр кертергә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны:

-ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

-җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм эшләвен тәэмин итү, җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

-җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

-җирлек чикләрендә халыкны электр һәм су белән тәэмин итүне оештыру;

-җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар булдыруга тотарга.

2. Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге гражданнарының җыен нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Актаныш авыл җирлеге»бүлегендә урнаштырырга.

Совет рәисе,
Актаныш авыл җирлеге Башлыгы Э.Н.Фәттахов